Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабрь 2020 ел №8

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата бүләкләү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 нче номерлы карары нигезендә

Габдрахман авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 24 августындагы 53 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 57 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Әлмәт муниципаль районының
Габдрахман авыл җирлеге муниципаль
хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| «Вазыйфаның исеме» | унберенче төркем хезмәт хакы, сум |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 17247,0 |
| Авыл башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 16902,0 |

1.2.«Җирле үзидарәнең даими нигездә
үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы
вазыйфаи затларын айлык акчалата бүләкләү күләме"

| «Вазыйфаның исеме» | унберенче төркем хезмәт өчен түләү буенча авыл җирлекләрендә айлык акчалата түләү күләме, сум |
|---|---|
| Башлык | 17253,0 |
| Башлык урынбасары | 12397,0 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Габдрахман авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Габдрахман авыл җирлеге
Башлыгы Р.Ш.Мотаһиров